МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ____17/о______

П Р И К А З　　　　　　　　　　　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

«__16___»______01________2025_

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге генераль планы проектын әзерләү турында» 2024 елның 23 маендагы 128/о номерлы боерыгы нигезендә, 2024 елның 20 сентябреннән 2024 елның 8 октябренә кадәр уздырылган гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм аларның нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге генераль планын (кушымтада) расларга.

2. Территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсенең төньяк-көнбатыш районнарны үстерү бүлегенә (Р.С.Минһаҗевка) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

«Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына торак пунктлар чикләре урнашу урынының график

тасвирламасы һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең координаталары исемлеге булган торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләрне әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып биш эш көне эчендә электрон рәвештә җибәрүне;

әлеге боерыкны Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында аны бастырып чыгару датасыннан 10 календарь көннән артмаган чорда урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н.Кудряшев

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2025 елның
16 гыйнварындагы 17/о
номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль
районының Борнак авыл җирлеге
генераль планы**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ

**Территориаль планлаштыру турында нигезләмә**

Казан, 2025

## Генераль планның текст һәм график материаллары исемлеге:

| № | Атамасы | Бит/битләр № |
|---|---|---|
| | **1 том Генераль план** | |
| | Текст материаллары | |
| 1 | Территориаль планлаштыру турында нигезләмә | |
| | График материаллар | |
| 2 | Җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы М1:10000 | 1/7 |
| 3 | Торак пунктлар чикләре картасы (шул исәптән төзелеп килүче торак пунктлар чикләре картасы) М1:10000 | 2/7 |
| 4 | Функциональ зоналар картасы М1:10000 | 3/7 |
| | Кушымта | |
| 5 | Шәһәр төзелеше кодексының 23 ст. 5.1 п. каралган белешмәләр (китерелми) | |
| | **2 Том Генераль планны нигезләү буенча материаллар** (китерелми) | |
| | Текст материаллары | |
| 1 | Аңлатма язуы | |
| 2 | Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм территорияне инженерлык әзерлеге буенча чаралар, гражданнар оборонасы буенча чаралар, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чаралар исемлеге. Аңлатма язуы | |
| | График материаллар | |
| 3 | Территорияне заманча файдалану картасы М1:10000 | 4/7 |
| 4 | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы М1:10000 | 5/7 |
| 5 | Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр, гражданнар оборонасы чаралары картасы М1:10000 | 6/7 |
| 6 | Инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары картасы М1:10000 | 7/8 |
| 7 | Территорияләрнең инженерлык әзерлеге картасы М1:10000 | 8/8 |

# ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ** ........ **4**

**2. УРНАШТЫРУ ӨЧЕН ПЛАНЛАШТЫРЫЛА ТОРГАН ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАРНЫҢ ТӨРЛӘРЕ, БИЛГЕЛӘНЕШЕ ҺӘМ ИСЕМНӘРЕ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР, АЛАРНЫҢ ТӨП ХАРАКТЕРИСТИКАЛАРЫ, АЛАРНЫҢ УРНАШУ УРЫНЫ, ШУЛАЙ УК ТЕРРИТОРИЯЛӘРДӘН ФАЙДАЛАНУНЫҢ МАХСУС ШАРТЛАРЫ БУЛГАН ЗОНАЛАРГА ХАРАКТЕРИСТИКАЛАР, ӘГӘР ШУШЫ ОБЪЕКТЛАРНЫ УРНАШТЫРУГА БӘЙЛЕ РӘВЕШТӘ МОНДЫЙ ЗОНАЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ ТАЛӘП ИТЕЛСӘ** ........ **6**

2.1. АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ ........ 6

2.2. ТОРАК ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ ........ 7

2.3. ХАЛЫККА СОЦИАЛЬ ҺӘМ МӘДӘНИ-КӨНКҮРЕШ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ ОБЪЕКТЛАРЫН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ ........ 9

2.4. ИНЖЕНЕРЛЫК ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ ........ 11

**3. ФУНКЦИОНАЛЬ ЗОНАЛАРНЫҢ ПАРАМЕТРЛАРЫ, ШУЛАЙ УК АЛАРДА УРНАШТЫРУ ӨЧЕН ПЛАНЛАШТЫРЫЛА ТОРГАН ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАР, РЕГИОНАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАР, ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР, ЛИНИЯ ОБЪЕКТЛАРЫННАН ТЫШ** ........ **14**

**4. БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ УРНАШТЫРУ ӨЧЕН ПЛАНЛАШТЫРЫЛА ТОРГАН ФЕДЕРАЛЬ БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ОБЪЕКТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР** ........ **19**

**5. БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ УРНАШТЫРУ ӨЧЕН ПЛАНЛАШТЫРЫЛА ТОРГАН РЕГИОНАЛЬ БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ОБЪЕКТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР** ........ **20**

## КЕРЕШ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге генераль планы проектлауга йөкләмә нигезендә «ГК-ГРУПП» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ГК-ГРУПП» ҖЧҖ) тарафыннан эшләнде.

Генераль план – шәһәр төзелеше стратегиясен, тормыш эшчәнлеге мохитен булдыру шартларын, җирлек территорияләрен үстерү юнәлешләрен һәм чикләрен, җирлек составындагы торак пунктларның чикләрен билгеләүне һәм үзгәртүне, территорияләрне функциональ зоналаштыруны, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне, мәдәни мирас объектларын һәм махсус саклanучы табигать территорияләрен саклап калуга, экология һәм санитария иминлегенә карата шәһәр төзелеше таләпләрен билгели торган территориаль планлаштыру документы.

Борнак авыл җирлеген территориаль планлаштыру Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла һәм Борнак авыл җирлеген үстерү бурычларын һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне комплекслы хәл итүгә юнәлдерелгән.

Генераль план гамәлгә ашыруның проект этаплары белән 20 елга әзерләнгән:

1) I этап (беренче чират) - 2034 ел;
2) II этап (хисап срогы) - 2044 ел.

Борнак авыл җирлеге чиге «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән.

Борнак авыл җирлеге составына бу Закон нигезендә Борнак (җирлекнең административ үзәге), Карык-Серма, Яңа Тау, Иске Торҗа авыллары керә.

Борнак авыл җирлеге генераль планында торак пунктларның чикләрен үзгәртү каралмаган.

Әлеге генераль план материаллары Борнак авыл җирлегендә җирдән файдалану кагыйдәләрен һәм территорияне планлаштыру документларын, социаль-икътисадый үсешнең комплекслы программаларын, Борнак авыл җирлеге территорияләрендә инженер-транспорт җиһазлары системаларын үстерүнең тармак схемаларын эшләгәндә, шулай ук муниципаль һәм төбәк әһәмиятендәге җитештерү һәм социаль объектлар төзү өчен мәйданчыклар сайлаганда кулланыла.

## 2. Урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларның төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары, аларның урнашу урыны, шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә

Борнак авыл җирлеге чикләрендә урнаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге әлеге генераль планны, гамәлдәге муниципаль программаларны нигезләү материаллары нигезендә төзелгән. Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар турында мәгълүматлар әлеге бүлектә китерелде.

### 2.1. Агросәнәгать комплексын үстерү буенча җирле әһәмияттәге чаралар исемлеге

Борнак авыл җирлеге генераль планында исәпләнгән срокка кадәр тәкъдим ителә:

- Карык-Серма авылы янындагы мөгезле эре терлек фермасының гамәлдә булмаган территориясен, өлешчә авыл хуҗалыгы җирләре итеп үзгәртеп оештыру, шулай ук территориянең калган өлешендә авыл хуҗалыгы җитештерүен перспективалы үстерү мәйданчыгын булдыру;
- Иске Торҗа авылы янындагы дуңгыз фермасының эшләми торган территориясен өлешчә авыл хуҗалыгы җирләре итеп үзгәртеп оештыру, шулай ук территориянең калган өлешендә авыл хуҗалыгы җитештерүен перспективалы үстерү мәйданчыгын булдыру;
- Борнак авылы янындагы яшелчә саклагычның эшләми торган территориясен рекультивацияләү, авыл хуҗалыгы җирләре итеп үзгәртү;
- Борнак авылы янында эре мөгезле терлекләр фермасы төзү (хәвефлелекнең III классы, 1,2 мең башка кадәр эре мөгезле терлек);
- Борнак авылы янында авыл хуҗалыгы производствосын перспективалы үстерү мәйданчыкларын оештыру куркынычлыкның V классыннан югары түгел.

### 2.2. Торак инфраструктурасын үстерү буенча җирле әһәмияттәге чаралар исемлеге

Борнак авыл җирлеге генераль планында яңа торак төзелеше мәйданчыклары Борнак, Иске Торҗа һәм Карык-Серма авылларында тәкъдим ителә.

*Беренче чиратта* торак төзелеше өчен генераль планны гамәлгә ашыру буенча җирлектә 15,4 га территория каралган:

1. Борнак авылы (торак пунктның гамәлдәге чикләрендә):
- 6,94 га мәйданда гомуми мәйданы 4,858 мең кв.м (48 кишәрлек) булган индивидуаль торак йортлар төзү;

2. Иске Торҗа авылы (торак пунктның гамәлдәге чикләрендә):
- 5,46 га мәйданда гомуми мәйданы 3,822 мең кв.м (38 кишәрлек) булган индивидуаль торак йортлар төзү;

3. Карык-Серма авылы (торак пунктның гамәлдәге чикләрендә):

- 3 га мәйданда гомуми мәйданы 2,1 мең кв.м (21 кишәрлек) булган индивидуаль торак йортлар төзү;

Торак төзелеше өчен генераль планны гамәлгә ашыруның *исәпләнгән срогына* җирлектә 14,415 га территория каралган:

1. Борнак авылы (торак пунктның гамәлдәге чикләрендә):

- 7 гектар мәйданда гомуми мәйданы 4,9 мең кв.м булган (49 кишәрлек) индивидуаль торак йортлар төзү.

2. Иске Торҗа авылы (торак пунктның гамәлдәге чикләрендә):

- 5 га мәйданда гомуми мәйданы 3,5 мең кв.м (35 кишәрлек) булган индивидуаль торак йортлар төзү;

3. Карык-Серма авылы (торак пунктның гамәлдәге чикләрендә):

- 2,415 га мәйданда гомуми мәйданы 1,691 мең кв.м (16 кишәрлек) булган индивидуаль торак йортлар төзү.

Генераль планны гамәлгә ашыруның хисап срогына торак төзелешенең гомуми күләме 20,871 мең кв.м тәшкил итәчәк.

1 нче таблица

Борнак авыл җирлеге территориясендә торак инфраструктурасын үстерү чаралары исемлеге

| т/с | Торак пунктының исеме | Объектның исеме | Чара төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Гамәлгә ашыру сроклары | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәл-дәге | Өстәмә | Беренче чираты | Хисап чоры | |
| Җирле әһәмияттәге чаралар (җирлек) | | | | | | | | | |
| 1 | Борнак авылы | торак пунктның гамәлдәге чикләрендә торак фонды | яңа төзелеш | га | - | 13,94 | + | + | Борнак авыл җирлеге генераль планы |
| | | | | мең кв.м | - | 9,758 | | | |
| 2 | Иске Торҗа авылы | торак пунктның гамәлдәге чикләрендә торак фонды | яңа төзелеш | га | - | 10,46 | + | + | Борнак авыл җирлеге генераль планы |
| | | | | мең кв.м | - | 7,322 | | | |
| 3 | Карык-Серма авылы | торак пунктның гамәлдәге чикләрендә торак фонды | яңа төзелеш | га | - | 5,42 | + | + | Борнак авыл җирлеге генераль планы |
| | | | | мең кв.м | - | 3,791 | | | |

## 2.3. Халыкка социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын үстерү буенча җирле әһәмияттәге чаралар исемлеге

Борнак авыл җирлеге территориясендә урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге мәгариф объектлары

2 нче таблица

| № | Объектның төре | Чара төре | Объектның исеме | Объектның төп характеристикалары* | Объектның урнашу урыны/ функциональ зона | Төзелеш чираты, ел | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристика |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәгариф объектлары | Реконструкция | Башлангыч мәктәп-балалар бакчасы, аның составында: | Сыйдырышлылыгы – 131 | Борнак авылы/ махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы | 2034 кадәр | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар билгеләү таләп ителми |
| | | | - мәктәп | Сыйдырышлылыгы – 96 урын | | | |
| | | | - балалар бакчасы | Сыйдырышлылыгы – 35 урын | | | |
| | | | - балалар иҗаты түгәрәкләре | Сыйдырышлылыгы – 29 урын | | | |

* - объектның төп характеристикалары проектлауның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелә

Борнак авыл җирлеге территориясендә урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге физик культура һәм спорт объектлары

3 нче таблица

| № | Объектның төре | Чара төре | Объектның исеме | Объектның төп характеристикалары* | Объектның урнашу урыны* / функциональ зона | Төзелеш чираты, ел | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристика |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Физик культура һәм спорт объектлары | Төзелеш | Спорт-ял итү комплексы, аның составында:<br>- спорт заллары | Мәйданы – 299 м2 | Борнак авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2034 кадәр | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар билгеләү таләп ителми |
| | | | - яссы корылмалар | Мәйданы – 0,3 га | | | |
| | | | - авыл мәдәният йорты | Егәрлеге – 57 урын | | | |
| | | | - сәүдә предприятиеләре | Сәүдә мәйданы – 302 м2 | | | |
| | | | - гомуми туклану предприятиеләре | Утырту урыннары – 54 | | | |
| | | | - көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре | Эш урыннары – 5 | | | |
| | | | - Саклык банкы бүлекчәсе | Операция урыны – 1 | | | |
| | | | - полициянең участок вәкаләтлесе (алга таба – УПП) | Егәрлеге – 1 УПП | | | |

* - объектның төгәл саны, урыны, төп характеристикалары проектлауның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелә

## 2.4. Инженерлык инфраструктурасын үстерү буенча җирле әһәмияттәге чаралар исемлеге

4 нче таблица

| № | Объектның төре | Чара төре | Объектның исеме | Объектның төп характеристика-лары* | Объектның урнашу урыны* / функциональ зона | Төзелеш чираты, ел | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристика |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | Су белән тәэмин итү объектлары | Төзелеш | Су алу корылмасы | Проект белән билгеләнә | Борнак авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | Россия Федерациясе дәүләт баш санитария табибының 2002 елның 14 мартындагы 10 номерлы карары СанПиН 2.1.4.1110-02 «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчәргә яраклы сүүткәргечләрнең санитар саклык зоналары», 2.2 пункт: санитар саклау зонасының беренче поясы чиге, сакланган җир асты суларыннан файдаланганда, су алудан кимендә 30 м кабул ителә, җитәрлек дәрәҗәдә сакланылмаган җир асты суларыннан файдаланганда – 50 м ким булмаган ераклыкта |
| 2 | | Төзелеш | Су алу корылмасы | Проект белән билгеләнә | Иске Торҗа авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | |
| 3 | | Төзелеш | Су алу корылмасы | Проект белән билгеләнә | Карык-Серма авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | |
| 4 | Җылылык белән тәэмин итү объектлары | Төзелеш | Блоклы-модульле котельный (алга таба – БМК) | Проект белән билгеләнә | Борнак авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | РФ Баш дәүләт санитария табибының 2007 елның 25 сентябрендәге 74 номерлы карары СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 «Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар саклык зоналары һәм санитар классификациясе», 10.4 пункт: санитар саклык зонасы – 100 м. |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Газ белән тәэмин итү объектлары | Төзелеш | Газ көйләгеч пунктлар, шкаф көйләгеч пунктлар (алга таба – ПРГ) | Проект белән билгеләнә | Борнак авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы карары, 7 пункт: сак зонасы – 10 м |
| 6 | | Төзелеш | ПРГ | Проект белән билгеләнә | Иске Торҗа авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | |
| 7 | | Төзелеш | ПРГ | Проект белән билгеләнә | Карык-Серма авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | |
| 8 | Электр белән тәэмин итү объектлары | Төзелеш | 10/0, 4 кВ трансформатор подстанцияләре (алга таба – ТП) | Проект белән билгеләнә | Борнак авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында" 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары, 23 пункт: сак зонасы – 10 м |
| 9 | | Төзелеш | ТП | Проект белән билгеләнә | Иске Торҗа авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | |
| 10 | | Төзелеш | ТП | Проект белән билгеләнә | Карык-Серма авылы/ Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | 2044 кадәр | |

* - объектның төгәл саны, урыны, төп характеристикалары проектлауның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелә

**3. Функциональ зоналарның параметрлары, шулай ук аларда урнаштыру өчен планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектлар, региональ әһәмияттәге объектлар, җирле әһәмияттәге объектлар турында белешмәләр, линия объектларыннан тыш**

Әлеге генераль планның функциональ зоналаштыру структурасы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны территориаль планлаштыру документларында тасвирлауга һәм чагылдыруга таләпләр раслау һәм Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2016 елның 07 декабрендәге 793 г номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип тану турында» 2018 елның 09 гыйнварындагы 10 номерлы боерыгы белән расланган Федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны территориаль планлаштыру документларында тасвирлауга һәм чагылдыруга карата таләпләр нигезендә билгеләнгән.

Борнак авыл җирлеге генераль планында кулланыла торган функциональ зоналар параметрлары

5 нче таблица

| № | Функциональ зона исеме | Функциональ зонаның билгеләнеше һәм параметрлары тасвирламасы | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар, объектның төп характеристикалары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы күбесенчә индивидуаль торак йортлар, йорт яны җир кишәрлекләре булган йортлар (шәхси ярдәмче хуҗалык), хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә һәм мәдәни-көнкүреш, коммуналь һәм социаль хезмәт күрсәтүнең беренчел баскычында объектлар һәм аларга бәйле объектлар, шулай ук тиешле инженерлык һәм транспорт инфраструктурасын төзү өчен каралган.<br>Функциональ зона параметрлары:<br>- төп бинаның иң чик катлары: 3 (мансардалысын да кертеп);<br>- төзелеш коэффициенты: 0,2-0,3. | Объектларны әлеге нигезләмәнең 2 бүлеге нигезендә урнаштыру (ИТТ, спорт-ял итү комплексы, су алу корылмасы, БМК, ПРГ һәм ТП) |
| 2 | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона гомумшәһәр үзәген төзү, эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге объектларны, сәүдә объектларын, гомуми туклану объектларын, коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, җитештерү һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектларга хезмәт күрсәтү өчен каралган.<br>Функциональ зона параметрлары:<br>- төп бинаның иң чик катлары: 5 (мансардалысын да кертеп);<br>- төп корылманың иң чик биеклеге: 20 м;<br>- төзелеш коэффициенты: 1. | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3 | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы күбесенчә социаль билгеләнештәге объектлар, шул исәптән мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, гомуми белем бирү оешмаларының, өстәмә белем бирү оешмаларының аерым объектлары, мәдәният һәм сәнгать, сәламәтлек саклау, социаль билгеләнештәге объектлар, физик культура һәм массакүләм спорт объектлары, гыйбадәт биналары, корылмалар, янәшәдәге инженерлык һәм транспорт белән тәэмин итү объектларын урнаштыру өчен каралган.<br>Функциональ зона параметрлары:<br>- төп бинаның иң чик катлары: 5 (мансардалысын да кертеп);<br>- төп корылманың иң чик биеклеге: 20 м;<br>- төзелеш коэффициенты: 0,8. | - |
| 4 | Җитештерү зонасы | Җитештерү зонасы күбесенчә җитештерү предприятиеләрен, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасын, шулай ук мондый зоналарда урнашырга рөхсәт ителә торган коммерция объектларын урнаштыру өчен каралган.<br>Функциональ зона параметрлары:<br>- төзелеш коэффициенты: 0,8 кадәр. | - |
| 5 | Инженерлык инфраструктурасы зонасы | Инженерлык инфраструктурасы зонасы башлыча су белән тәэмин итү объектларын, су агызу объектларын, җылылык белән тәэмин итү объектларын, газ белән тәэмин итү объектларын, электр белән тәэмин итү объектларын, элемтә объектларын, башка төр инженерлык инфраструктурасын, шул исәптән коммуникацияләрне үткәрү коридорларын урнаштыру өчен каралган. | - |
| 6 | Транспорт инфраструктурасы зонасы | Транспорт инфраструктурасы зонасы башлыча автомобиль транспорты объектларын, башка төр транспорт инфраструктурасы объектларын, урам-юл челтәре объектларын һәм аларга бәйле объектларны урнаштыру өчен каралган. | - |
| 7 | Авыл хуҗалыгы җирләре зонасы | Авыл хуҗалыгы җирләре зонасы авыл хуҗалыгы җирләрендә авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүгә бәйле хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру; авыл хуҗалыгы терлекләрен көтүлек итү; кыр юллары өчен каралган. | - |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 8 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең | Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең җитештерү зонасы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, авыл хуҗалыгы, крестьян-фермер | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җитештерү зонасы | хуҗалыгы алып бару, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасының яңәшәдәге объектларын үстерү өчен каралган.<br>Функциональ зона параметрлары:<br>- төзелеш коэффициенты: 0 кадәр, | |
| 9 | Урман зонасы | Урман зонасы дәүләт урман фонды җирләрен урнаштыру өчен каралган. | - |
| 10 | Зиратлар зонасы | Зиратлар зонасы җирләү урыннарын урнаштыру өчен каралган. | - |
| 11 | Махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр зонасы | Махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр зонасы санитар саклык зоналарында, санитар аралыкларда яшеллек яисә махсус билгеләнештәге башка үсентеләрне утырту өчен каралган. | - |
| 12 | Калдыкларны туплау һәм күмү зонасы | Калдыкларны җыю һәм күмү зонасы калдыкларны күмү һәм утильләштерү объектларын урнаштыру өчен каралган. | - |
| 13 | Акваторияләр зонасы | Акваторияләр зонасы өске су объектларын урнаштыру өчен каралган. | - |
| 14 | Башка зоналар | Башка зоналар гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләрен, урам-юл челтәрен урнаштыру өчен каралган. | - |

## 4. Борнак авыл җирлеге территориясендә урнаштыру өчен планлаштырыла торган федераль билгеләнештәге объектлар турында белешмәләр

6 нчы таблица

| № | Объектның төре | Объектның исеме | Объектның төп характеристикалары | Объектның урнашу урыны/ функциональ зона | Төзелеш чираты, ел |
|---|---|---|---|---|---|
| - | - | - | - | - | - |


## 5. Борнак авыл җирлеге территориясендә урнаштыру өчен планлаштырыла торган региональ билгеләнештәге объектлар турында белешмәләр

7 нче таблица

| № | Объектның төре | Объектның исеме | Объектның төп характеристикалары | Объектның урнашу урыны | Төзелеш чираты, ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Каты коммуналь калдыкларны (алга таба – ККК) урнаштыру объектлары | Каты көнкүреш калдыклары чүплегеn авыл хуҗалыгы җирләре итеп үзгәртеп бетерү (рекультивацияләү) | Мәйданы – 0,529 га | Борнак авыл җирлеге | 2034 |


# ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## КАРТА ПЛАНИРУЕМОГО РАЗМЕЩЕНИЯ ОБЪЕКТОВ МЕСТНОГО ЗНАЧЕНИЯ



# ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## КАРТА ФУНКЦИОНАЛЬНЫХ ЗОН




ЭКСПЛИКАЦИЯ

| № п/п | Наименование | Статус |
|---|---|---|
| 1 | БУРНАК | |
| 1.1 | МБОУ «Бурнакская начальная школа-детский сад» | сущ. |
| 1.2 | Исполнительный комитет Бурнакского сельского поселения, сельский дом культуры, библиотека | сущ. |
| 1.3 | Фельдшерско-акушерский пункт, почта | сущ. |
| 1.4 | Мечеть | сущ. |
| 1.5 | Контора ООО «Борнак» | сущ. |
| 1.6 | Магазин | сущ. |
| 1.7 | Памятник | сущ. |
| 1.8 | Столовая (ООО "Борнак") | сущ. |
| 1.9 | Игровая площадка | сущ. |
| 2 | СТАРАЯ ТУРЬЯ | |
| 2.1 | Фельдшерско-акушерский пункт, памятник, игровая площадка | сущ. |
| 2.2 | Магазин | сущ. |
| 2.3 | Сельский клуб | сущ. |
| 3 | КАРЕК-СЕРМА | |
| 3.1 | Сельский клуб, библиотека, игровая площадка, памятник | сущ. |
| 3.2 | Фельдшерско-акушерский пункт | сущ. |
| 3.3 | Магазин | сущ. |
| 4 | ТЕРРИТОРИЯ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | |
| 4.1 | Ферма КРС (ООО "Борнак") | сущ. |
| 4.2 | Склады | сущ. |
| 4.3 | Летний лагерь для скота | сущ. |
| 4.7 | Карьер (торфоразработки) | сущ. |
| 4.8 | Ферма КРС III класса опасности | проект |
| 4.9 | Резервная территория объектов производства IV класса опасности | проект. |
| 4.10 | Резервная территория объектов производства V класса опасности | проект. |

УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

| сущ. | проект. | Наименование |
|---|---|---|
| | | ГРАНИЦЫ ЕДИНИЦ АДМИНИСТРАТИВНО-ТЕРРИТОРИАЛЬНОГО ДЕЛЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
| | | Граница сельского поселения |
| | | Граница населенного пункта |
| | | ФУНКЦИОНАЛЬНЫЕ ЗОНЫ |
| | | ЖИЛЫЕ ЗОНЫ |
| | | Зона застройки индивидуальными жилыми домами |
| | | ОБЩЕСТВЕННО-ДЕЛОВЫЕ ЗОНЫ |
| | | Зона специализированной общественной застройки |
| | | Многофункциональная общественно-деловая зона |
| | | ПРОИЗВОДСТВЕННЫЕ ЗОНЫ, ЗОНЫ ИНЖЕНЕРНОЙ И ТРАНСПОРТНОЙ ИНФРАСТРУКТУР |
| | | Производственная зона |
| | | Зона инженерной инфраструктуры |
| | | Зона транспортной инфраструктуры |
| | | ЗОНА СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННОГО ИСПОЛЬЗОВАНИЯ |
| | | Зона сельскохозяйственных угодий |
| | | Производственная зона сельскохозяйственных предприятий |
| | | ЗОНА РЕКРЕАЦИОННОГО НАЗНАЧЕНИЯ |
| | | Зона лесов |
| | | ЗОНА СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ |
| | | Зона озелененных территорий специального назначения |
| | | Зона кладбищ |
| | | Зона складирования и захоронения отходов |
| | | ЗОНА АКВАТОРИЙ |
| | | Зона акваторий |
| | | ИНЫЕ ЗОНЫ |
| | | Иные зоны |
| | | ПОВЕРХНОСТНЫЕ ВОДНЫЕ ОБЪЕКТЫ |
| | | Водоток (река, ручей, канал) |
| | | Водоток (река, ручей, канал) |
| | | ОБЪЕКТЫ ТРАНСПОРТНОЙ ИНФРАСТРУКТУРЫ |
| | | Автомобильные дороги регионального или межмуниципального значения |
| | | Автомобильные дороги местного значения |
| | | Улицы в жилой застройке |
| | | Мостовое сооружение |
| | | ОБЪЕКТЫ ТРУБОПРОВОДНОГО ТРАНСПОРТА И ИНЖЕНЕРНОЙ ИНФРАСТРУКТУРЫ |
| | | Линии электропередачи 35 кВ |
| | | Линии электропередачи 10 кВ |
| | | Трансформаторная подстанция (ТП) |
| | | Газопровод распределительный высокого давления |
| | | Пункт редуцирования газа (ПРГ) |
| | | Водопровод |
| | | Артезианская скважина |
| | | Базовая станция |
| | | ОБЪЕКТЫ УТИЛИЗАЦИИ, ОБЕЗВРЕЖИВАНИЯ, РАЗМЕЩЕНИЯ ОТХОДОВ |
| | | Объект утилизации, уничтожения биологических отходов |
| | | Места несанкционированного размещения отходов производства и потребления |
| | | МЕСТА ПОГРЕБЕНИЯ |
| | | Кладбище |
| | | Объект регионального значения |
| | | Объект местного значения |
| | | Границы земельных участков, стоящих на кадастровом учете |

# ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## КАРТА ГРАНИЦ НАСЕЛЕННЫХ ПУНКТОВ (В ТОМ ЧИСЛЕ ГРАНИЦ ОБРАЗУЕМЫХ НАСЕЛЕННЫХ ПУНКТОВ)

